СОВЕТ
АЗЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д. 22,
с. Азеево, 423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКЪЯР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы,22 йорт
Акъяр авылы, 423190

тел.: (8-84348) 3-71-31, факс: (8-84348)3-7-61, Azeev.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль
районы Акъяр авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2023 елның 10 апреле №34-112

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының 23.11.2012 № 22-55 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Азеевка авыл җирлеге Советының 23.11.2012 № 22-55 карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә (карарлар редакциясендә: 17.12.2016 № 20-42; 5.02.2021 №7-20):
1.1. 30 статьяның 1.1 өлешендәге «җир кишәрлекләрен һәм капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре» икенче абзацын түбәндәге эчтәлектәге пунктчалар белән тулыландырырга:
"шәхси торак төзелеше;
шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт яны җир участогы);
коммуналь хезмәт күрсәтү;
коммуналь хезмәтләр күрсәтү;
базар;
кибет».
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында « бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, «Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/.
3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге башкарма комитетына закон белән билгеләнгән срокта Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлегенең әлеге карарын һәм җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен территориаль планлаштыруның Федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга: http://fgistp.economy.gov.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Акъяр авыл җирлеге Советының Законлылык, җирдән файдалану һәм территорияләрне төзекләндéрү буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Акъяр
авыл җирлеге башлыгы

Д.С.Гайнуллин